Республика Татарстан

**СОВЕТ ШАРЛИАРЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная, д. 57, д.Шарлиарема
423372
Телефон: 4-57-55

Татарстан Республикасы

**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, йорт 57, Шәрләрәмә авылы
423372
Телефон: 4-57-55

ОГРН 1121651003671 ИНН/КПП 1636007010/163601001 ОКТМО 92653482

КАРАР № 72 24 август 2018 ел

**Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының 2007 елның 07 июлендәге 13 номерлы карары белән расланган «Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыю һәм алып китү тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1997 елның 10 февралендәге 155 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 июнендәге 766 номерлы карары нигезендә Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. 2 бүлекнең 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сыек көнкүреш калдыклары» - хуҗалык - халыкның тереклек эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән һәм үзәкләштерелгән су чыгару системасына тоташтырылмаган (технологик яктан тоташтырылмаган) һәм агып төшүче суларны кабул итү һәм туплау өчен билгеләнгән корылмаларга һәм җайланмаларга ташлана торган көнкүреш агым сулары.»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет рәисе Н.Н.Хузина